# КАРАР

**24 ноябрь 2022 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Октябрина поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, сход 24 ноябрь 2022 елда утте.:

"Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары,18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр; 18 яшькә кадәрге балаларын тәрбияләүче ялгыз әниләр; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләр; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Октябрина поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 55 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Лесная урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;
- территорияне кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- Октябрина поселыгында энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;
- Лесная урамындагы чишмәне төзекләндерү(материаллар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү );
- -Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган авылдашларына һәйкәл төзү (материаллар алу, эш өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү );

« БЕЗ РИЗА» « БЕЗ КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 9 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 7 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 7 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Октябрина поселогында халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр; 18 яшькә кадәрге балаларын тәрбияләүче ялгыз әниләр; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләр; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Октябрина поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә расларга булганнар:

- Лесная урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- территорияне кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

- Октябрина поселогында энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;

- Лесная урамындагы чишмәне төзекләндерү(материаллар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү );

--Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган авылдашларына һәйкәл төзү (материаллар алу, эш өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү );

- карарны кабул ителгән итеп санарга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгъләмова